ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

23 04 2024 г. № 434

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы балалары булган Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2022 елның 10 октябрендәге 700 номерлы Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. «Махсус хәрби операциядә катнашучы һәм Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2022 елның 10 октябрендәге 700 номерлы Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карарына (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча өстәргә:

«3) Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының каникул вакытында укучыларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыруны гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмалары тарафыннан оештырылган лагерьларда гражданнарның югарыда күрсәтелгән категорияләренә ата-ана взносларын түләүдән азат итү».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы А.Х. Гарифуллинга йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Булатов

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН